КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2019 ел, 20 сентябрь г.Казань № 855

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ваклап сату базарлары хакында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2006 ел, 30 декабрь, ФЗ-271 нче Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 ел, 13 июль, 285 нче карары белән расланган Татарстан Республикасының ваклап сату базарларында сәүдә урынын бирү турында шартнамә төзү тәртибенә үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Ваклап сату базарлары хакында һәм Россия Федерациясе Хезмәт кодексына үзгәрешләр кертү турында» 2006 ел, 30 декабрь, ФЗ-271 нче Федераль законны тормышка ашыру чаралары хакында» 2007 ел, 13 июль, 285 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2007 ел, 28 сентябрь, 517 нче; 2010 ел, 22 гыйнвар, 25 нче; 2018 ел, 29 декабрь, 1268 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Татарстан Республикасының ваклап сату базарларында сәүдә урынын бирү турында шартнамә төзү тәртибенә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктта «Шартнамә төзү» сүзләреннән соң «һәм сатучы карточкасын алу» сүзләрен төшереп калдырырга;

әлеге Тәртипкә теркәлгән кушымтада:

3.2.1 нче пунктны төшереп калдырырга;

3.2.25 нче пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.2.25. Сәүдә урынында сәүдә урыны бирү турындагы шартнамәнең яки аның күчермәләренең һәм шәхесне раслый торган документның булуын тәэмин итәргә һәм аларны эчке эшләр органнары, тикшерүдә тоту һәм күзәтчелек органнары хезмәткәрләре, шулай ук базар белән идарә итүче компаниянең вәкаләтле хезмәткәрләре таләбе буенча күрсәтергә.».

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин